

«Зубово-Поляна районында Татар Лунданы дигән татар авылы бар. Аны еш кына Искил дип атыйлар. Бу авыл кvп кенә танылган кешеләрнен бишеге. Татар Лундан авылы турында беренче тапкыр 1366 елда искә алына»,- дип язылган Горенка авылы китапханәсе сайтында. Безгә Румия Абдулла кызы Деликамова, Зубово-Поляна районы Горенка авыл жирлеге мәдәни-ял итv vзәге китапханәчесе, таныш. Ул туплаган материал тvбәндә.

Хакимиятнен исламга каршы карашларына карамастан, 1926 елда революциягә кадәрге мәчет vз эшен алып баруын дәвам итә. Шул вакыт бу округта vз эшчәнлеген дәвам иткән бердәнбер мәчет һәм анда азан да әйтелгән. Мәчетне ашлык склады буларак кулланылган чор да булган. Вакыт узгач, жирле халык коче белән косметик ремонт ясалган. Мәчет янадан эшен дәвам иткән. Зур моселман бәйрәмнәрендә бирегә Искил һәм кvрше авыллар ир-атлары бергәләп намазга жыелганнар. Мулла булып Бурятия шәһәренен педагогия университетында тарих белгечлеге буенча белем алган Шамиль Ибраһим улы Чинакаев торган. Ул 1938 елда туган. 80 нче елларда ул vзенен укытучылык эшчәнлеген Зубово-Поляна районы Татар Лунданынын башлангыч мәктәбендә башлый. Монда ул 30 елга якын балаларга ан-белем биргән. Бу вакытка кадәр 16 ел Кочетовка авылында башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. 90 нчы елларда Шамиль Ибраһимович мәктәптә дә, мәчеттә дә берьюлы эшли. Балаларны ул гомуми белем бирv фәннәре белән генә тvгел, ә Коръән белән дә таныштыра. 2006 елда ул мәктәптән китә һәм бик аз вакыт мулла гына булып эшләргә олгерә. Шамиль Ибраһим улы Чинакаев, авыру сәбәпле, шул ук 2006 елда вафат була. Бу вакыйгадан сон, рухи остаз булмаганга, мәчет vз эшчәнлеген туктата.

Татар Лундан авылы ир-атлары кvрше татар авылы Кочетовкага йори башлыйлар. Үз вакытында иске мәчет ябыла һәм кvп еллар узгач кына иске кибет бинасын мәчет итеп бирәләр. Бу бинаны бергәләп ремонтлыйлар һәм бvгенге конгә кадәр ир-атлар зур дини бәйрәмнәрдә бергә намазга нәкъ шунда жыелалар.

Зубово-Поляна районында татарлар жәберләнмиләр һәм башка халыклар белән тигезлектә яшиләр. Авыл туган телне, милли гореф-гадәтләрне һәм традицияләрне саклау очен унайлы мохит булып тора.

Н.ХӘЛИЛ әзерләде